ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37,
423964,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы,
37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

N 2 03.11.2023

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын (бер тапкыр түләүләрне) кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 маддәләренә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы карары белән кабул ителгән "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 14, 81 маддәләренә таянып,Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 сентябрендәге 11 санлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамакм авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында"гы нигезләмә нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 17 ноябрендә 11.00 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Көрәш-Бүләк авылы, Совет урамы, 9А йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, I төркем инвалидлардан; Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым (бер тапкыр түләүләр) кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы:

- Көрәш-Бүләк торак пунктында су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын төзү (скважинаны бораулау, шамбо урнаштыру, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (санкцияләнмәгән чүплекне бетерү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

-җирлек эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының

рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru; Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча www.yutaza.tatar.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көненнән үз көченә керә

«Бәйрәкәтамак авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Ф.Г.Лукманов